КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 831

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлекләренә ия булу, алардан файдалану, алар белән эш итү мәсьәләләре буенча мәҗбүри хәбәрләрне бастырып чыгару өчен, шулай ук коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының гомуми җыелышларын үткәрү турында хәбәрләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чаралары исемлеген раслау турында» 2004 ел, 2 апрель, 161 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 14 май, 324 нче; 2019 ел, 21 март, 196 нчы, 2019 ел, 28 август, 725 нче, 2021 ел, 2 август, 674 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) преамбулада «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 июль, ФЗ-217 нче Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 декабрь, ТРЗ-114 нче Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге ТРЗ-35 номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы" сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр милкенә түләүсез сатып алу тәртибен раслау турында» 2019 ел, 30 март, 243 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милке» сүзләрен «муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 29 июль, ФЗ-217 нче Федераль законны кабул итүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 декабрь, ТРЗ-114 нче Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып бару өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге ТРЗ-35 номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясы" сүзләренә алмаштырырга;

беренче абзацта «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милке» сүзләрен «муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яки яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе чикләрендә урнашкан гомуми файдаланудагы мөлкәтне Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яки Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр милкенә түләүсез сатып алу тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милке» сүзләрен «муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре» сүзләрен «территорияләрендә гражданнарның бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территориясе урнашкан муниципаль берәмлекләр (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре милке» сүзләрен «муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «территорияләрендә гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару территориясе урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (алга таба - бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе)" сүзләрен «территориясендә бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе урнашкан муниципаль берәмлек милке» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

«б» пунктчасында «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә территориясендә бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе урнашкан муниципаль берәмлек милке,» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә вәкаләтле орган Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез мөлкәт алу турында йә Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә мөлкәтне түләүсез алудан баш тарту турында карар кабул итә.»;

12 пунктта:

беренче абзацта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

«ж» пунктчасында «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «территориясендә бакчачылык яисә яшелчәчелек территориясе урнашкан муниципаль берәмлек милке,» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән муниципаль милеккә түләүсез мөлкәт сатып алу турында карар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда вәкаләтле орган Татарстан Республикасы дәүләт милкенә яисә муниципаль милеккә түләүсез мөлкәт сатып алу турында карар кабул итә.»;

14 пунктта «яисә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге милке» сүзләрен «яисә муниципаль милек» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин